КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 9 август г.Казань № 635

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк (республика) һәм җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларына, ачыкланган мәдәни мирас объектларына, тарихый-мәдәни кыйммәткә ия булган объектларга, мәдәни мирас объекты билгеләренә ия булган объектларга, хуҗалык ягыннан үзләштерелергә тиешле җир кишәрлекләренә кагылышлы тарихый-мәдәни экспертизага түләү күләмен билгеләү тәртибен раслау турында» 2013 ел, 16 август, 566 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк (республика) һәм җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларына, ачыкланган мәдәни мирас объектларына, тарихый-мәдәни кыйммәткә ия булган объектларга, мәдәни мирас объекты билгеләренә ия булган объектларга, хуҗалык ягыннан үзләштерелергә тиешле җир кишәрлекләренә кагылышлы тарихый-мәдәни экспертизага түләү күләмен билгеләү тәртибен раслау турында» 2013 ел, 16 август, 566 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 16 август, 566 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «(республика)», «тарихи-мәдәни кыйммәткә ия булган объектларга» сүзләрен төшереп калдырырга;

1 пунктта «(республика)», «тарихи-мәдәни кыйммәткә ия булган объектларга» сүзләрен төшереп калдырырга;

2 пунктта «Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгына» сүзләрен «Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитетына» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Төбәк (республика) һәм җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларына, ачыкланган мәдәни мирас объектларына, тарихый-мәдәни кыйммәткә ия булган объектларга, мәдәни мирас объекты билгеләренә ия булган объектларга, хуҗалык ягыннан үзләштерелергә тиешле җир кишәрлекләренә кагылышлы тарихый-мәдәни экспертизага түләү күләмен билгеләү тәртибендә:

исемендә «(республика)», «тарихи-мәдәни кыйммәткә ия булган объектларга» сүзләрен төшереп калдырырга;

1 пунктта «(республика)», «тарихи-мәдәни кыйммәткә ия булган объектларга» сүзләрен төшереп калдырырга;

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин